Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы
Карары

«19» сентябрь 2019ел № 111

Җирле референдум үткәрү
инициативасы турында

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе, 2019 елның 18 нче сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының 43 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (кондезге бүлектә укучы студентлардан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 (өч йоз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:
- Олы Салтык авылында юлларны ремонтлау,
- Олы Мәрәтхуҗа авылында зират коймасын ремонтлау,
- каты көнкүреш калдыклары полигоннарын норматив хәлгә китерү,
- Олы Салтык авылында кое ремонтлау,
- Даныш авылында кулне чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы,

Ленин урамы, 61 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авылы җирлеге
Башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авылы җирлеге
Советы рәисе Х.Х.Ибәтов